Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның 28 апрелендәге №244

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2023 елның 14 августындагы 160 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 декабрендәге 471-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 15 маендагы 99-ФЗ номерлы карары , «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 104, 105, 106 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ :

1. Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2023 елның 14 августындагы 160 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 1 пунктындагы 15 пунктчада «Россия Федерациясе субъекты» сүзләреннән соң «муниципаль мәгариф оешмаларында спортка әзерлекнең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру,» сүзләрен өстәргә;

1.2. 41 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10.1 пунктча өстәргә:

«10.1) аларга чит ил агенты статусы алу;»;

1.3. 52 статьяның 6 пунктының икенче абзацында «Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «муниципаль мәгариф оешмаларында спортка әзерлекнең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыра,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 6 өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы урынбасары И.Т. Гыйниятовка йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Советы рәисе Н.А.Вазыйхов